**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЕЛАУР АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Елаур ав. КАРАР

«22» октябрь 2020 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Елаур җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 2 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Елаур авылы, Үзәк урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авылының Үзәк урам буенча 1-85нче, Яшьләр урамы буенча 3-25нче, Пионер урамы буенча 2-5нче, Комсомол урамы буенча 5-23нче, Чапаев урамы буенча 1-22 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 3 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Елаур авылы, Центральная урамы 25 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йортында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авылының Ленин урамы буенча 1-69нчы, Калинин урамы буенча 1-68нче, Елга арьягы урамы буенча 4-14нче, Җиңүнең 40 еллыгы урамы буенча 2-10 нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Елаур авылында яшәүчеләр җыенын уздыру өчен исемлекне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлегенең Елаур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Октябрина торак пункты чикләрендәге авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (юл өслеген күтәрү, таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре).

Октябрь т.п. су алу өчен пирс әзерләү ( килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Елаур торак пунктында су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охототникова